*Ә. Нәбиуллина, КДУ доценты*

## Синтаксик белемнәрне тикшерү чарасы буларак тестлар технологиясе

Хәзерге вакытта югары уку йортларында татар телен укытуның яңа формаларына һәм алымнарына зур игътибар бирелә. Бу юнәлештә студентларның белем һәм күнекмәләрен тикшерүдә объектив һәм уңайлы ысулларның берсе булган тестлардан киң файдалану әһәмияткә ия.

Тестлар технологиясенең өстенлеге шулардан гыйбарәт:

▪ Җавапның дөреслеген ачыклаганчы, сорауга яңадан әйләнеп кайтып, аны үзгәртү, төзәтү мөмкинлеге бар.

▪ Тестларны эшләүгә бирелгән вакыт бетсә, җавап бирмичә калдырып киткән биремнәргә җавап дөрес түгел дип санала.

▪ Җавапның дөреслеген тикшереп барырга мөмкин.

• Тестларны эшләп бетергәннән соң, тиз арада нәтиҗәне белергә мөмкин: куелган билге, тест эшләүгә киткән вакыт арасы, тесттагы гомуми биремнәр саны, студент җавап биргән биремнәр саны, дөрес һәм дөрес булмаган җаваплар саны [Бухмин 2007: 14].

Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты студентларының синтаксик белемнәрен тикшерү чарасы буларак Ф.С. Сафиуллина, Г.Ә.Нәбиуллина, З.Н.Кириллова, З.В. Шәйхразиева тарафыннан "Синтез" программасына нигезләнеп төзелгән компьютер тестлары кулланылышка кертелде[1].

Тестлар, синтаксистан билгеле бер күләмдәге материалны гамәли үзләштергәч, белем сыйфатын тикшерүгә юнәлтелә. Моңа кадәр аз вакыт эчендә 5-10 сораудан торган өйрәтү тестларын һәр дәрестә эшләп алырга мөмкин. Курс ахырында гомуми контроль тестлардан файдаланырга мөмкин.

Алар барлык өйрәнелгән теоретик һәм гамәли сорауларны үз эченә алалар. Мондый тестлар, гадәттә, гади җөмлә синтаксисы, кушма җөмлә синтаксисы һәм текст синтаксисын өйрәнеп бетергәч үткәрелә. Контроль тестлар үткәргәндә, эшне 2 этапка бүлеп оештырырга мөмкин. Башта студентларга теоретик материалны гомумиләштереп кабатлау тестлары бирелә. Укучы теоретик белем һәм күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсен тикшереп бәяләгәннән соң, гамәли материалны үз эченә алган тестларга күчә ала.

Тестлар дүрт типтагы биремнәрдән тора:

1) дөрес җавапны билгеләү, ягъни ябык тестлар;

2) күп нокталар урынына төшеп калган терминны уйлап язу, ягъни ачык тестлар;

3) тәңгәлләштерү тестлары;

4) җавапларны эзлекле тәртиптә урнаштыру тестлары.

Югарыда әйтелгәнчә, бу төр биремнәр гади җөмлә, кушма җөмлә һәм текст синтаксисыннан белем һәм күнекмәләрне тикшерү максатыннан чыгып кулланыла. Гади җөмлә синтаксисын үткәндә, җөмләдә сүзләр бәйләнешен, сүзтезмәләрне, җөмлә кисәкләрен, гади җөмлә төрләрен тикшерү максат итеп куела. Кушма җөмлә синтаксисын өйрәнгәндә исә, бигрәк тә гади һәм кушма җөмләләрне аеру, кушма җөмләләр составындагы компонентларның санын, кушма җөмләләрнең төрен, бәйләүче чараларны һәм җөмләнең схемасын дөрес билгеләү күздә тотыла. Укыту тәҗрибәсеннән чыгып, түбәндәге мисалларны китерә алабыз.

**I.** Дөрес җавапны билгеләү тибындагы тестлар җавапны сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәрдән гыйбарәт. Студент тәкъдим ителгән дүрт җавапның берсен сайлап алырга тиеш. Мәсәлән,

1. Билгеле үтәүчеле фигыль җөмләләрдә баш кисәк кайсы грамматик формада килә алмый?

---

[1] Программа "Синтез": http://192.168.5.110:8000

1) инфинитив
2) -асы формалы сыйфат фигыль + иде
3) -ган формалы сыйфат фигыль + бар/юк
4) хәл фигыль

2. Иянең төзелеше буенча нинди төрләре була?
1) гади, катлаулы
2) гади, катлаулы, тезмә
3) гади, тезмә
4) гади, кушма

3. Раслау җөмләне табыгыз.

1) *Безнең өчен бу сорау — сорау түгел (М. Мәһдиев).*
2) *Су тирәнәя төште (М. Әмир).*
3) *Ат карышмады (М. Әмир).*
4) *Әбине һич онытасым юк (Ф. Хөсни).*

**II.** Ачык тестларда күп нокталар урынына төшеп калган терминны уйлап язу сорала. Бу тестлар кыска җаваплар таләп итүче биремнәрдән тора. Мисал өчен,

1. Бер сүзнең икенче сүзне ачыклап килүе нигезендә **...** мөнәсәбәт оеша.
2. Хәбәрлекле мөнәсәбәт нигезендә **...** барлыкка килә.
3. Оештыручы үзәге бер генә булган һәм икенчесен өстәп булмый торган җөмлә **...** җөмлә дип атала.
4. Җөмләдә сүзләрнең кире тәртибе **...** дип атала.
5. Җөмләнең берәр кисәген җөмлә ахырына чыгарып, өстәп әйтү күренеше **...** дип атала.

**III.** Тәңгәлләштерү характерындагы тестларда бирелгән билгеләмәләрдән, синтаксик анализдан чыгып, дөрес җавапларны туры китерү сорала. Мәсәлән, җөмләләргә бирелгән характеристикадан чыгып, җавапларны тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| 1) *Сүзнең көче искиткеч зур икән (Ә. Еники).* | А) гади, бер составлы,гомуми үтәүчеле, җәенке, тулы, хикәя, тойгылы түгел, раслау җөмлә |
| 2) *Ике уйла, бер сөйлә (Мәкаль).* | Б) гади, ике составлы, җәенке, тулы, хикәя, тойгылы түгел, раслау җөмлә |
| 3) *Умырзая, җыйдык, кошлар сайравын тыңладык, рәхәтләнеп ял иттек (Г. Мөхәммәтшин).* | В) гади, ике составлы, җәенке, ким, хикәя, тойгылы түгел, раслау җөмлә |
| 4) *Сүзләр, Кук гөмбәзендәге йолдызлар мириадасы кебек, күренә дә, күренми дә, беленә дә, беленми дә, сүнә дә, сүнми дә, ерак та, якын да, үлә дә, үлми дә (М. Галиев).* | Г) гади, ике составлы, җәенке, тулы, тиңдәш хәбәрләр белән катлауландырылган, хикәя, тойгылы түгел, инкяр җөмлә |

**IV.** Җавапларны билгеле бер эзлеклелектә урнаштыру тестлары**.** Бу очракта студент бирелгән сорауга җавап вариантларын билгеле бер хронологик яисә синтаксик берәмлекләрне кимү-арта бару тәртибендә урнаштырырга тиеш була. Мисал өчен,

1. Синтаксис буенча язылган хезмәтләрне хронологик тәртиптә языгыз.
   1) Җ.Вәлиди “Татар теленең грамматикасы”
   2) В.Хангилдин “Татар грамматикасы”

3) Г.Ибраһимов “Татар нәхүе”

4) А.Казем-Бек “Общая грамматика турецко-татарского языка»

2. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрне компонентлары кими бару тәртибендә урнаштырыгыз.

*1) Күреп торасыз: фуражы бар хуҗалыклар салам юктан интегә (Х.Хәйруллин).*

*2) Мәхәббәт туса, чәчәк бөресе ачылгандай, бары үзеннән-үзе һәм үз вакыты белән генә туа ала ул (Ә.Еники).*

*3) Бу фаҗига булганнан соң, байтак еллар үтте, шулай да эзе һаман тирән иде әле: дошманнар, сүз чыккан саен, мыскыл итеп телгә алалар (Г.Ибраһимов).*

*4) Җир-суы бар җирен сөйләр, ил-йорты бар илен сөйләр, ил-йорты юк ниен сөйләр (Мәкаль).*

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, тестлар ярдәмендә укучыларның синтаксик белемнәрне үзләштерүен тикшерү эзлекле бер системаны тәшкил итә. Синтаксис дәресләрендә тестлар белән эшләү студентларның белем сыйфатын тикшерү мөмкинлеге бирә. Шуңа күрә дә дәресләрдә, башка грамматик биремнәр белән беррәттән, заман таләп иткән компьютер тестларыннан файдалануга да тиешле игътибар бирелергә тиеш, дип саныйбыз.

Әдәбият

1. Бухмин В.С. Пособие по разработке банков тестовых заданий в соответствии с требованиями министерства образования и науки Российской Федерации / В.С. Бухмин, Л.А. Габдрахманова, Е.А. Соколова. – Казань: КГУ, 2007. – 15с.

2. Васильев В.И. Культура компьютерного тестирования. Форма тестовой ситуации и формирования теста. Часть IV: Учеб. пособие / В.И. Васильев, Т.Н. Тягунова. – Москва: МГУП, 2005. – 83 с.

3. Куклин В.Ж. О компьютерной технологии оценки качества знаний / В.Ж.Куклин, В.И.Мешалкин, В.Г.Наводнов, Б.А.Савельев // Высшее образование в России. – 1993. - №3. – С. 146-153.

4. Садовничий В.А. Компьютерная система проверки знаний студентов / В.А. Садовничий // Высшее образование в России. – 1994. - №3. – С.30-31.

5. http://www.ast-centre.ru

6. http://192.168.5.110:8000